ГЛАВА ЛЕБЕДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЕДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Лебедино **КАРАР**

**03.12.2021е.** **№10**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлегенең Новоспасск авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге Уставының нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.
2. Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлегенең Новоспасск авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 17 декабрендә 2 этапта уздыру график нигезендә билгеләргә. (Кушымта).
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Лебедино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларга вак таш җәю һәм карап тоту;
- техниканы - тракторны карап тоту;

- авыл җирлегенең торак пунктында урамнарны яктыртуны карап тоту.

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Лебедино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебедино авыл җирлеге башлыгы** **Ю.И. Тюкарев**

Кушымта

# ГРАФИК

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлегендә Новоспасск авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын этаплап үткәрү

| № п/п | Үткәрү датасы | Үткәрү вакыты | Үткәрү урыны | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 17.12.2021 | 10:00ч. | Авыл клубы бинасы Новоспасск авылы, Некрасов ур., 18А | Октябрьнең 35 еллыгы ур. Некрасов ур. |
| 2 | 17.12.2021 | 15:00ч. | Авыл клубы бинасы Новоспасск авылы, Некрасов ур., 18А | Үзәк ур., 8 Март ур. |